КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 15 май г.Казань № 704

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 5 август, 681 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 31 август, 931 нче, 2022 ел, 5 ноябрь, 1178 нче, 2023 ел, 20 апрель, 511 нче, 2024 ел, 26 декабрь, 1215 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның физик культура һәм спорт өлкәсендә чаралар, массакүләм мәдәни чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасы халкы өчен бәйрәмнәр һәм социаль юнәлештәге башка чаралар оештыруга, үткәрүгә һәм аларда катнашуга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

50 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

56 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

57 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау

турында» 2021 ел, 11 сентябрь, 859 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 6 сентябрь, 963 нче; 2022 ел, 15 декабрь, 1340 нчы, 2023 ел, 20 апрель, 503 нче, 2024 ел, 14 март, 146 нчы, 2024 ел, 28 декабрь, 1233 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Спорт чараларын, теннисны пропагандалау, популярлаштыру һәм алга таба үстерү чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

50 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

56 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

57 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 1 декабрь, 1161 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 15 август, 826 нчы, 2022 ел, 17 декабрь, 1364 нче, 2023 ел, 20 апрель, 512 нче, 2024 ел, 27 декабрь, 1224 нче, 2025 ел, 26 август, 638 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларның Татарстан Республикасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү өчен спорт объектлары бирүгә бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (кире кайтару) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктка «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

50 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

56 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

57 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин